ТЕРРИТОРИАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ
САБИНСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА РАЙОНЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел./ факс (84362) 2-40-66

# К А Р А Р

**25 ноябрь 2019 г.** **№ 91/1**

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы «Шәмәрдән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2019 елның 24 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе күрсәткечләре нигезендә, Татарстан Республикасы Саба районының территория сайлау комиссиясе (ИКМО) 2019 елның 24 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында, аның түбәндәгеләр нигезендә беркетмә төзеде:

Тавыш бирү тәмамланган вакытка референдумда катнашучылар исемлекләренә 4983 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны - 2568, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән референдумда катнашучыларның 51.54%ын тәшкил итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: “Әйе” позициясе өчен 2003 (77.99%) референдумда катнашучылар тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; “Юк” позициясе өчен 560 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 21.81 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының территория сайлау комиссиясе (ИКМО) карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә 2019 елның 24 ноябрендә узган референдумны, референдум нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салымны 300 (өч йөз) сум күләмендә кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә ризалыгымны танырга:

- Кырбаш авылында балалар мәйданчыгын һәм аның тирә-юнен төзекләндерү;
- Мичәнбаш авылын су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләвен проектлаштыру;
- Шәмәрдән авылында җирләү урыннарын тәртиптә тоту;
- Шәмәрдән авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Шәмәрдән авылында җәяулеләр юлларын төзү?» кабул ителгән дип танырга.

3. «Саба таннары» газетасында җирле референдум нәтиҗәләрен бастырырга яисә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба районының Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Саба районы
Территориаль сайлау комиссиясе
рәисе — М.В.Галиуллин

МП

Татарстан Республикасы
Саба районы
Территориаль сайлау комиссиясе
секретаре — К.Ф.Хисамиев